Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«14» ноябрь 2020 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бикүле авылындагы 3нче номерлы зират коймасын ремонтлау һәм карап тоту;

- Бикүле торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау (грунт-вак таш катнашмасы һәм вак таш җәю, сатып алу, ташу, җәю)

Халык җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова